Югары Ырга авыл җирлеге башкарма комитеты

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы

№ 15 карар

Югары Ырга авылы, 2016 елның 3 октябре

Референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 2 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 өлешенең 1 пункты, «җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясындагы 1 пунктының «в», Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы « Югары Ырга авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ::

1.Югары Ырга авыл җирлеге Советы белән берлектә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлеге территориясендә җирле референдум үткәрү инициативасын тәкъдим итәргә:

«2016 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә риза буласызмы?:

- Югары Ырга авылы зиратын койма белән әйләндереп алу

- Яңа Ырга авылында юлларны ремонтлау

- Югары Ырга һәм Яңа Ырга авылларындагы юлларны кардан чистарту

-Югары Ырга авылында һәм авылда урам читләреннән чүп үләннәре чабу

Яңа Ырга

ӘЙЕ ЮК".

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлегенең Югары Ырга авылы, М.Җәлил урамы, 18 йорт; Яңа Ырга авылы, Мәктәп урамы, 48 йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Югары Ырга Авыл Җирлеге Башлыгы
авыл җирлеге башлыгы
Балык Бистәсе
муниципаль район башлыгы Баһаветдинов Р.Н.